**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 апрелендәге 1307 номерлы карары**

## Казан шәһәренең социаль яллау килешүе буенча бирелгән муниципаль торак фондындагы торак урыннарын алмаштыру документларын карап тикшерү буенча иҗтимагый торак комиссиясен төзү турында

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 8 июнендәге 1586 номерлы «Муниципаль торак фондының социаль яллау килешүе нигезендә бирелгән торак урыннарын алмаштыру белән бәйле документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына (алга таба – карар) таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәренең социаль яллау килешүе буенча бирелгән муниципаль торак фондындагы торак урыннарын алмаштыру документларын карап тикшерү буенча иҗтимагый торак комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

| | |
|---|---|
| Закиров Ринат Альберт улы | комиссия рәисе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасары |
| Закирова Аделя Таһир кызы | комиссия рәисе урынбасары, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесенең торак фондын исәпкә алу бүлеге башлыгы |
| Савенкова Елена Анатольевна | комиссия секретаре, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна |

| | |
|---|---|
| | учреждениесенең торак фондын исәпкә алу бүлеге баш белгече |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Романенко Денис Валерьевич | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесенең юридик бүлек башлыгы |
| Смагина Елена Николаевна | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары |
| Трифонова Юлия Борисовна | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы |
| Гафиятуллина Айгөл Рөстәм кызы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең юридик бүлек башлыгы |

2. Әлеге карар белән расланган Социаль яллау килешүе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә комиссия эшен оештырырга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. комиссия эшчәнлеге белән аның рәисе җитәкчелек итә, ул комиссия утырышларын алып бара, комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә. Комиссия рәисе урында булмаганда, аның вазифаларын комиссия рәисе урынбасары башкара;

3.2. комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми санының кимендә яртысы катнашса, комиссия карар кабул итәргә хокуклы (кворум) була;

3.3. карар комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм, карар кабул итүнең тиешле нигезләрен күрсәтеп, бәяләмә рәвешендә өч нөсхәдә рәсмиләштерелә. Әгәр карар кабул иткәндә тавышлар саны тигез булса, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Кабул ителгән карар белән

килешмәгән очракта, комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язма рәвештә белдерергә һәм аны бәяләмәгә беркетергә хокуклы.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**